**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«17» гыйнвар, 2024 ел

№ 22

«Төзәтү эшләре рәвешендәге хөкем ителгәннәр җәзасын үтәү, мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәзаны үтәү урынын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 04 маендагы 294 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2023 елның 26 гыйнварындагы 64 номерлы үзгәрешләр белән)

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Төзәтү эшләре рәвешендәге хөкем ителгәннәр җәзасын үтәү, мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәзаны үтәү урынын билгеләү турында» 2022 елның 04 маендагы 294 номерлы карарын (2023 елның 26 гыйнварындагы 64 номерлы үзгәрешләр белән) туры китерү максатыннан, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Карарга 1 нче, 2 нче кушымталарны яңа редакциядә әлеге карар кушымтасы нигезендә бәян итәргә.
2. Россия Федерациясе Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Питрәч муниципаль филиалына әлеге карарның икенче нөсхәсен кушымта белән җибәрергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http://pestreci.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Д. Сабитовка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — В.И. Никитин